**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26.10.2022 ел** **№ 1031**

**2023 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы «Татарстан Республикасы балаларга сәнгати-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты:

1. 2023 елга расларга:

кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларга сәнгати-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,65 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына өстәмә белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.10.2022 1031 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (1 укучыга елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри юнәлеш |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореографик сәнгать | авыл җирлеге | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |